РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТА РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

18.05.2026 №186/Бк/к

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» 19.04.2019 елның 19 апрелендәге 195/Бк/к карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» (29.12.2025 редакциясендә), 2006 елның 21 апрелендәге 59-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» (28.12.2024 редакциясе), 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законнар, 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы (23.07.2025 редакциясендә), нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» 19.04.2019 елның 19 апрелендәге 195/Бк/к карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 5.1.1.8 пунктындагы 4 абзацын һәм 1.7 пунктындагы 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү барышында җирләрдән файдалануга һәм саклауга карата Россия Федерациясе законнарында административ һәм башка җаваплылык каралган мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта, контроль (күзәтчелек) чарасы актында мондый хокук бозу турында мәгълүмат «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә күрсәтелә. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы органнарның вазыйфаи затлары дәүләт җир күзәтчелеге органына муниципаль җир

контролен гамәлгә ашыру кысаларында контроль (күзәтчелек) чарасын уздыру нәтиҗәсендә төзелгән күрсәтелгән актның күчермәсен җибәрәләр. Муниципаль җир контроле органнары җирләрдән файдалануга һәм аларны саклауга карата, шул исәптән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирә ала.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе Л.Р. Шакирҗанов